Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл жирлеге советы
423066 **ЯңаКармәт** авылы
Муса Җәлил урамы,15а нче йорт
тел. 4-92-33 факс

Совет Новокиреметского сельского поселения Аксубаевского муниципального района
42306 с.Новая Киреметь
улица Мусы Джалиля, д.15а
тел. 4-92-33 факс

Муса Җәлил урамы, 15а нче йорт
Яңа Кармәт авылы , 4203066

ул. Мусы Джалиля, д 15а,
с.Новая Киреметь, 423066

Тел. (8-84344-4-92-33) ОГРН 1021605359709,
ОКПО 04311599, ИНН/КПП 1603001197/160301001
E-mail: *Nkir.Aks@tatar.ru*

КАРАР

2023 елның 24 ноябре № 4

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче Яңа Дума авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының “Яңа Кармәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2019 елның 5 ноябрендәге 98 номерлы карарына таянып, түбәндәге сораулар буенча 2023 елның 17 ноябрендә һәм 24 ноябрендә Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Яңа Дума авылында узган гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1."2024 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Дума авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм хәрби хезмәткә мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:

1)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- кышкы чорда Яңа Дума авылы эчендәге юлларны карап тоту, урамнарны кардан чистарту буенча килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

- Яңа Дума урамнары буенча юллар салу өчен товарлар (грунт-вак һәм вак таш) сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр күрсәтү;

2) Торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле керүен тәэмин итү;

- массакүләм, мәдәни-күңел ачу чараларын үткәрү өчен товарлар, җиһазлар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;

"ӘЙЕ"  " ЮК"  "ТЫЕЛЫП КАЛДЫ"

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 268 гражданин кертелгән, тавыш бирүдә 182 гражданин катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 167 кеше тавыш бирде;
- «юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 15 кеше тавыш бирде.
- "тыелып калды" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче Яңа Дума авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре-чын.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә:

1."2024 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Дума авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм хәрби хезмәткә мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:

1)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- кышкы чорда Яңа Дума авылы эчендәге юлларны карап тоту, урамнарны кардан чистарту буенча килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

- Яңа Дума урамнары буенча юллар салу өчен товарлар (грунт-вак һәм вак таш) сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр күрсәтү;

2) Торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына иркле керүен тәэмин итү;

- массакүләм, мәдәни-күңел ачу чараларын үткәрү өчен товарлар, җиһазлар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү

3. Әлеге карарны Яңа Кармәт авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә,http://aksubaevo.tatar.ru Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәмhttp://pravo.tatarstan.ru/Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы  И. Р. Шакиров